КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 сентябрь г.Казань № 834

Акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларының исемен үзгәртү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәгеләрнең исемен үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«Акыл үсеше артта калган балалар өчен Югары Отар балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесенең исемен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Югары Отар балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесе итеп;

«Акыл үсеше артта калган балалар өчен Дербышка балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесенең исемен «Психик бозылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән Дербышка балалар интернат йорты» дәүләт казна учреждениесе итеп.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына календарь көннәрдә исәпләнә торган 90 көн эчендә бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт казна учреждениеләре уставларына тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин